Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советы
КАРАРЫ

19 февраль 2019 ел №140

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Башлыгының 2018 елдагы эшчәнлек нәтиҗәләре һәм 2019 елга бурычлар турында отчеты

Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Башлыгы А.Р. Хәйруллинның 2018 елдагы эшчәнлек нәтиҗәләре һәм 2019 елга бурычлар турында отчетын тыңлаганнан һәм карап тикшергәннән соң Әлмәт шәһәр Советы, шәһәр Башлыгының «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясе Законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы, Әлмәт муниципаль районы Уставы нигезендә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыруын билгеле.

2018 ел Әлмәт муниципаль районы өчен ике истәлекле дата – шәһәр төзелүнең 65 еллыгы һәм Татарстан Республикасында нефть ятмаларын сәнәгый эшкәртә башлауның 75 еллыгы белән истә калды.

Шәһәр Башлыгының эшчәнлеге халыкның тормыш сыйфатын яхшырту һәм шәһәр инфраструктурасын үстерү өчен уңай шартлар тудыруга юнәлдерелгән иде.

Елның төп казанышлары: «Сыйфат өлкәсендә Россия Федерациясе Хөкүмәте премиясе» бәйгесендә һәм «Акыллы стратегия-акыллы шәһәр» номинациясендә бөтенроссия муниципаль стратегияләр бәйгесендә җиңү, «ЭКОлидер» республика бәйгесендә «Әйләнә-тирәлекне саклау өлкәсендәге казанышлары өчен» номинациясендә беренче урын, «Татарстан Республикасының иң төзек торак пункты» республика бәйгесенең III дәрәҗә дипломын алу, Әлмәтнең спорт һәм ял инфраструктурасы буенча Россиянең 10 шәһәре исемлегенә керүе.

Әлмәт шәһәр Советы, шәһәр Башлыгының каланың, социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш кертүен билгеле.

Югарыда бәян ителгәннәрдән һәм Әлмәт шәһәр районы Уставы нигезләмәләреннән чыгып

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре

Башлыгының 2018 елдагы эшчәнлек нәтиҗәләре һәм 2019 елга бурычлар турында отчетын исәпкә алырга.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырырга һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Шәһәр башлыгы А.Р. Хәйруллин